Казан шәһәре Совет  районы "Күп профильле 181 нче мәктәп"

# «Күкнең җиденче катында»

№7  март , 2022 нче  ел






## 8 нче март-язның беренче бәйрәме

Кояш нурларына, тамчылар чыңына төренеп март ае да килеп җитте. Табигатьнең язгы үзгәреш кичергән бер мәлендә без гүзәл затларыбызның иң күркәм бәйрәмен - 8 Март Халыкара хатын-кызлар көнен билгеләп үтәбез. Язгы кояш нурына күмелгән әлеге бәйрәмдә мәхәббәт, матурлык, ана назы, ягымлылык, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек, сабырлык, хатын-кызга ихтирам кебек мәңгелек кыйммәтләр чагылыш таба. Бу матур бәйрәм көнендә безнең ихлас котлауларыбызны кабул итегез.Язгы гөрләвекләр сезнең тормышыгызга җылылык, саулык-сәламәтлек, эшегездә уңышлар, күңел тынычлыгы, күтәренке кәеф, бәхет алып килсен!



Хөрмәтле Динә Альберт кызы!

Хөрмәтле  укытучыларыбыз!

Сезне 8 нче март белән котлыйбыз. Сезгә сәламәтлек, бәхет, мәхәббәт, яхшы укучылар һәм күбрәк ял телибез.

Хөрмәт белән , сезнең укучыларыгыз.

# “Алтын каләм”...



## Укучылар иҗаты

### Әнием-назлы гөлем.

Минем әниемнең исеме – Гөлназ. Исеменең мәгънәсе “назлы гөл”. Әниемне гөлләр белән чагыштырып була, ул көннән-көн яшәрә, чибәрләнә.

Әбием аңа Миләүшә исеме бирергә теләгән була, ләкин апасының кызы үз сүзендә нык тора: Гөлназ исемен куштыра. Әниемнең әйтүе буенча, ул үскәндә бик популяр исем була, сыйныфында 4 Гөлназ укый.

Әнием тумышы белән Балтач якларыннан. Белемне Балтач мәктәбендә ала. Мәктәпне яхшы билгеләргә тәмамлагач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты һәм чит телләр факультетына укырга керә. 3 ел укыгач, әнием Казанның бер мәктәбендә укытучы булып эшкә урнаша. 2 елдан диплом алып, шул мәктәптә үзенең укучылары белән эшләп кала.

Әнием кечкенәдән балаларны бик ярата. Хыялы- балалар белән эшләү була.

Хәзерге көндә кечкенә вакытындагы хыялы тормышка ашты, балалар бакчасында эшли. Үз эшенә карата бик төгәл. Гел эзләнә, яңалыкка омтыла. Әле кечкенә балаларына күп мәгълумат бирергә, барысына өйрәтергә, тормышка карата мәхәббәт тәрбияләргә ашыга.

Өйдә әнием таләпчән, безнең, 3 баласының, укымышлы, тәртипле, тыйнак, эшчән булуын тели. Төрле халык ашлары пешереп сыйлый, гөлләр үстерә. Җәй көне бакчада эшләргә ярата, яшелчәләр үстерә, көз көне бай уңыш ала.

Бәйли, чигә, өйдә дә гел яңалык кертеп тора.

Без әниебезне бик яратабыз. Ул дөньяда шундый бер генә.

Асланова Нәргиз

# Март аенда истәлекле даталар:

1 март

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановка 65 яшь (1957)

6 март

Композитор, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе һәм халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мансур Әхмәт улы Мозаффаровның тууына 120 ел (1902–1966)

8 март

Язучы Үзбәк Газиз улы Саттаровның тууына 100 ел (1922–1982)

9 март

Композитор, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рим Мәхмүт улы Хәсәновка 75 яшь (1947)

12 март

Язучы, галим, дәүләт эшлеклесе, Хезмәт Батыры Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимовның тууына 135 ел (1887–1938)

12 март

Актёр, Татарстан Республикасының халык артисты Марсель Бакир улы Җаббаровка 75 яшь (1947)

21 март

Артист, Татарстан Республикасының халык артисты Булат Нуретдин улы Сәләховка 70 яшь (1952)

24 март

Композитор, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Риф Вәҗетдин улы Ильясовның тууына 80 ел (1942–2017)

# Математика, физика, химия, биология атналыгы




Математика, физика, химия, биология – мәктәптә иң төп фәннәр булып тора.

**Физика** – табигать турындагы фән. Кеше – табигатьнең бер кисәге. Шуңа күрә дә мин үз укучыларымны эзләнү-тикшеренү эшләренә тартырга тырышам. Табигатьнең күпчелек законнарын укучыларым тәҗрибәләр, күзәтүләр ярдәмендә яңадан ача.

**Математика** - безне чолгап алган дөньяның санлы төзелеше турындагы фән.

**Химия** - матдәләр,аларның үзлекләре, матдәләр алмашы һәм бу әверелешләргә хас күренешләр турындагы фән.

Төгәл фәннәрнең әһәмияте турында бик күп сөйләп булыр иде. Аларның кайсын гына алсаң да, тормыштагы рольләре бик зур. Алар бер-берсен тулыландыралар, баеталар, гадиләштерәләр. «Чыгарылманың физик мәгънәсе», «Интегралны кәкресызыклы трапециянең мәйданын исәплләгәндә куллану» темаларына сокланып карамау мөмкин түгел! Биологиядән «Генетика» бүлеген генә карагыз әле сез! Искиткеч! Менә кайда ул гармония, матурлык!





**Редакциянең адресы:**
420101, Казан шәһәре,Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576

**Тираж** – 50 экз.

**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова Айсылу Фәрид кызы
**Редколлегия әгъзалары:**
Зактирова Азалия, Овезова Лэйлә, Сафина Камилла, Соколова София